Кукмара муниципаль районы
Кәркәүч авылы җирлеге Советы

Карар

2019 елның 28 ноябре № 30

«Физик затлар мөлкәтенә салым турында»
2014 елның 24 ноябрендәге 36 номерлы
Кәркәүч авылы җирлеге Советы
карарына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Салым кодексының 32 бүлеге нигезендә Кәркәүч авылы җирлеге Советы карар бирде:

1. Кәркәүч авылы җирлеге Советының «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» 2014 елның 24 ноябрендәге 36 номерлы карарына (Кәркәүч авыл җирлеге Советының 2015 елның 29 маендагы 24 номерлы, 2015 елның 13 октябрендәге 4 номерлы, 2018 елның 21 июнендәге 20 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2 пунктта:

а) 2 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2) фатирларга, фатир өлешләренә, бүлмәләргә карата – 0,2 процент»;

б) 3 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3) түбәндәгеләргә карата 0,3 процент:

- торак йортлар, торак йортларның өлешләре;

- составына бер генә булса да торак йорт кергән Бердәм күчемсез комплекслар;

- төзелеп бетмәгән объектлар, әгәр мондый объектларның билгеләнеше торак йорт булса;»

1.2. алдагы эчтәлекле 3.1 пунктын өстәргә:

«3.1. Физик затларның мөлкәтенә салым түләүдән азат итәргә:

1) 18 яшькә кадәрге биш һәм аннан да күбрәк балалары булган гражданнарны;

2) әлеге пунктның 1 пунктчасында күрсәтелгән гражданнарның балаларын;»

Әлеге карарны Татарстан Республикасының Рәсми хокукый мәгълүмат порталында www.pravo.tatarstan.ru адресы буенча, шулай ук Кәркәүч авылы җирлеге торак пунктлары территориясендә урнашкан махсус мәгълүмати стендларда урнаштырырга.

Әлеге карар 2020 елның 1 гыйнварыннан, әмма басылып чыккан көненнән соң кимендә бер ай узгач, үз көченә керә.

Кәркәүч авыл җирлеге башлыгы М.Ф.Зәйнетдинов